

3 октябрь 11:00
«Күңел дәфтәрләре»
Филология фәннәре докторы, әдәбият белгече Фоат Галимуллин белән очрашу
"79 нчы экология-технология лицее"


Шагыйрь түгелмен мин,
Мин – галим,
Ә шулай да шигырь язам
Нигә мин?
(Рифат Җамал)

Галимнең шигъри күңелен аңлау, яшь буынны әдәбият белгече белән таныштыру максатыннан 2024 елның 3 октябрендә Совет районының “79 нчы экология-технология лицее”нда филология фәннәре докторы, танылган әдәбият белгече, диктор, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, әдәбият фәне, әдәби тәнкыйть өлкәләрендә күпсанлы хезмәтләр, уку йортлары өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләр, уку әсбаплары язган автор Фоат ага Галимуллин белән “Күңел дәфтәрләре” дип исемләнгән очрашу үтте. Чарада 5-8 нче сыйныфларда укучы татар балалары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татар мәдәнияте белән кызыксынучы башка мөгаллимнәр катнашты. 50 елдан артык гомерен югары уку йортларында студентлар укытуга багышлаган галим, күңел түрендәге хис-кичерешләрен “Күңел дәфтәре”нә туплап барган икән. Лицей укучыларына әнә шул хакта сөйләде Остаз – шигырь язу серләренә төшендерде, “бәрхет тавыш иясе” укучыларга сәнгатьле сөйләм осталыгы буенча да киңәшләрен бирде.

Балачагы авыр сугыш елларына туры килсә дә, үсмер чагыннан ук китап уку белән мавыккан Фоат ага. Татар теле укытучысы Фоат абыйда телебезгә, мәдәниятебезгә мәхәббәт уяткан. Укучыларга биргән киңәше дә бик төпле иде галимнең – үз телегезгә булган хөрмәтне беркайчан да югалтмагыз, ана телегездә аралашып яшәгез, диде ул.

Әлеге истәлекле мизгелләр лицей укучылары күңелендә матур бер хатирә булып озак сакланыр дип ышанабыз.


3 октябрь 11:00
«Күңел дәфтәрләре»


«Күңел
дәфтәрләре»







